СОВЕТ
НАДЕЖДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НАДЕЖДИНО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.04.2026 Надеждино ав. № 17

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 34 номерлы Надеждино авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 декабрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 34 номерлы Надеждино авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 4 пунктчасының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күпфатирлы йорт проектлана торган, төгәлләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган салым салу объектларының;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/), Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларындабастырырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Надеждино авыл җирлеге Башлыгы Е.В.Савельева